# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
## Сәпәй авыл җирлеге Советы

Сәпәй авылы                    № 141                    «15» октябрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенең Генераль планы турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел № 131 - ФЗ Федераль закон, Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Генераль планы проектына 06.12.2017 ел №10-53/15595 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан килештерелгән уңай бәяләмә, 10.02.2018 ел авыл җирлегенең Генераль планы проекты турында фикер алышу буенча ачык тыңлауларның нәтиҗәләре нигезендә

Сәпәй авыл җирлеге Советы **карар чыгара:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге нең тәкъдим ителгән Генераль планын расларга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенең Генераль планы турында» 28.12.2012 ел №52 карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис                                                    Ф.Г. Галиева